Шәһәр күләмендә җәмгыять белеме фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре
2024-2025 нче уку елы
10-11 нчы сыйныфлар

Эш вакыты – 120 минут
Гомуми балл – 100

1. Сорауларга җавап бирегез. Әгәр сезнең җавабыгыз түбәндәге гыйбарә белән туры килсә, “<u>әйе”</u>, туры килмәсә, “<u>юк”,</u> дип билгеләгез. Җавапларыгызны таблицага языгыз. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 8 балл.

1.1. Россия Федерациясе Конституциясе безнең дәүләтебездә иң югары юридик көчкә ия.
1.2. Милли мәнфәгатьләр башка халыклар белән киңкүләм мәдәни элемтәләр урнаштыруны таләп итә.
1.3. Мәңгелек, үзгәрешсез хакыйкатьләр юк.
1.4. Фәнни революцияләр элек яшәп килгән теорияләрнең барысын да юкка чыгара.
1.5. Халык исәбен алу вакытында гражданнар тарафыннан бирелгән мәгълуматлар документлар күрсәтеп расланырга тиеш.
1.6 Иҗтимагый мөнәсәбәтләр җәмгыять белән табигать арасындагы мөнәсәбәтләрне үз эченә ала.
1.7. Олигополия өлкәсендә монополиягә караганда җитештерүчеләр күбрәк була.
1.8. Мәктәпнең үзешчән сәнгать ансамбле формаль булмаган төркемнең мисалы.

Җавап:

1.1.	1.2.	1.3.	1.4.	1.5.	1.6.	1.7.	1.8.

2. Төшеп калган сүзләрне языгыз. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 5 балл.
2.1. Дөньяда сәяси режимның өч төре яшәп килә:
А) демократик Б) _____, В) _____

2.2. Платон идарә итүнең дөрес формаларына түбәндәгеләрне кертә:
А) тимократия Б) олигархия В) _____, Г) _____

2.3. Җитештерү, _____, бүлү, куллану.

3. Бирелгән сүзләр рәте нинди принцип буенча төзелгән? Алар өчен уртак булган төшенчәне билгеләгез. Дөрес җавап өчен 2 балл. Барлыгы 6 балл.

3.1. Президентлык, армия, суд, прокуратура

Җавап: _____

3.2. Янгын куркынычлыгы кагыйдәләрен бозу, урамда сыра эчү, кошлар оясын җимерү

Җавап: _____

3.3. Машина йөртүче, академик, аспирант, Нобель бүләге лауреаты

Җавап: _____

4. Түбәндә китерелгән исемлектән дәүләт функцияләрен табып билгеләгез. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 3 балл.

1) Ил мәнфәгатьләрен халыкара мәйданда күрсәтү
2) Сайлауга кандидатларны тәкъдим итү
3) Дини оешмалар төзү (оештыру)
4) Ил иминлеген саклау
5) Бөлгенлеккә төшкән оешмаларның бурычларын акционерларга түләү
6) Закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятен үтәү

Сайлап алган җавапларыгызның цифрларын үсә бару тәртибендә языгыз.

Җавап: _____.

5. Түбәндә китерелгән исемлектән норматив хокукый актлар иерархиясен билгеләгез. Дөрес җавап өчен 7 балл. Бер ялгыш өчен 5 балл. 2 дән артык ялгыш булса – бәяләнми.

РФ Хөкүмәте боерыклары, Федераль законнар, РФ Конституциясе, Җирле үзидарә органнарының хокукый актлары, РФ Президенты указлары, Федераль конституциячел законнар, Министрлыкның һәм ведомстволарның норматив актлары



6. Аббревиатураны тулы итеп языгыз. Дөрес җавап өчен 1 балл. Максималь 5 балл.

Аббревиатура	Җавап
ЮХИДИ	
БДБ	
ҖЧҖ	
ТМП	
ММЧ	

7. Түбәндәге ситуацияләрне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз. Дәлилләрегезнең тулы һәм төгәл булуына карап, җавабыгыз 3 баллга кадәр бәяләнә. Барлыгы 6 балл.

7.1. 2024 елның 10 февралендә гражданин Хаиров үлгәннән соң анын мирасы ачыла. Ул 12 сотка җир участогына хужа булган. Хаировның варисчылары кызы Динә һәм улы Камил булып торалар. Ләкин Хаиров барлык милеген кызына васыять итә. Камил 2024 елның 10 июнендә 18 яшь тулгач, нотариаль конторога мирасны алу гаризасы белән мөрәҗәгать итә. Сезнеңчә Камилнең мирас алу мөмкинлеге бармы? Җавабыгызны аңлатыгыз.

Әгәр дә сез мөмкин дип исәпләсәгез, ул очракта Камилгә җирнең нинди өлеше бирелачәк.

Җавап:_____

7.2. Суд карары буенча урлау өчен иректән мәхрүм ителгән 15 яшьлек Газизов, суд карары буенча хокукый сәләтсез танылган 20 яшьлек Умаров һәм техникумда укучы 17 яшьлек Кәримов җирле үзидарә органнары сайлауларында катнашырга кертелмиләр. Бу очракта гражданнарның хокуклары бозылмыймы?

Җавап:_____

8. Түбәндәге икътисади мәсьәләләрне чишегез. Дөрес җавап өчен 2 балл. Барлыгы 4 балл.

8.1. Бу елны реаль тулай эчке продукт 2500 миллиард доллар тәшкил итте, ә аннан алдагы елда 2000 миллиард доллар иде. Быел икътисади күтәрелеш ничә процент булачак?

Җавап:_____

_____

8.2. "Нәүрүз" фирмасы товар ассортиментын киңәйтү исәбенә җитештерүне арттырырга булды. Продукция эшләп чыгару түбәндәге гомуми чыгымнарны таләп итте: бина өчен аренда – 100 мең сум, чимал – 400 мең сум, эш хакы – 100 мең сум, кадрлар әзерләү – 20 мең сум, ягулык – 20 мең сум, транспорт хезмәтләре – 10 мең сум. Даими һәм алмашучан чыгымнар суммасын исәпләп чыгарыгыз.

Җавап:_____

_____

_____

9. Текстны укыгыз һәм биремнәрне эшләгез. Барлыгы 15 балл.

СССР таркалып, яңа суверен дәүләтләр формалашкач, Татарстанда дәүләт *суверенитеты* турында декларация тормышка ашырылды. Республика тарафыннан үткәрелгән сәясәт, аерым алганда, республика *Дәүләт Советы*, РФ *Дәүләт Думасы*, халык депутатларының җирле Советларына сайлаулар нәтиҗәләре уртаклык позициясенең дөреслеген раслады.

Татарстан Республикасы *Конституциясе* нигезендә без күпмилләтле җәмгыять төзибез, анда кешенең кайсы милләткә каравы түгел, ә *граждан* булуы өстенлеккә ия. Шунлыктан һәр дәүләт хезмәткәре барлык халык мәнфәгатьләрен кайгырта.

1. **Курсив белән билгеләнгән терминнарга аңлатма (билгеләмә) бирегез (Һәрбер сүзгә дөрес һәм тулы аңлатма өчен 2 балл).**

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

2. Татарстан Республикасы Конституциясе кайчан кабул ителде (1 балл) һәм ул республика өчен нинди мөмкинлекләр һәм хокуклар бирде (4 балл)?

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

10. Түбәндә бирелгән текстагы хаталарны төзәтегез. Тапкан һәр хата өчен 1 балл. Дөрес төзәтү өчен 2 балл. Барлыгы 15 балл.

Федераль закон кешене, аның хокукларын һәм ирекләрен иң югары кыймммәт дип тану принцибын беркетә.

Безнең һәрберебез ил гражданы булып тора яки, билгеләнгән кагыйдәләргә таянып, гражданга әверелә ала. Үзебезнең дәүләт территориясендә туу һәм әти-әниләрнең ил гражданнары булу безгә Россия гражданы булырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш гражданлыкка кабул итәргә дә мөмкиннәр. Моның өчен кеше махсус гаризада гражданлыкка кабул итүне сорап мөрәҗәгать итә һәм карарны субъект җитәкчеләре чыгара.

14 яшькә җиткән һәр кеше дә мондый хокукка ия. Әмма монда бик мөһим шарт бар – кеше Россия Федерациясендә 10 ел дәвамында даими яшәгән булырга тиеш.

1997 елларда кертелгән паспорт кешенең Россия гражданы булуын раслаучы документ була. Россия гражданы булган кеше теркәлгән барлык хокукларга һәм бурычларга ия була. Безнең хокукларның һәм ирекләрнең төп гаранты булып Россия Федерациясе Хөкүмәте тора.

Җавап:

	Хата	Төзәтү
1.		
2.		
3.		
4.		
5.		

11. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чоры вакыйгаларын сүрәтләгән фотоларны сайлагыз. Аларның тәртип номерларын күрсәтегез һәм вакыйганың кайсы шәһәрдә булуын билгеләгез. Һәр дөрес җавап өчен 2 балл. (Дөрес номерны һәм шәһәрнең исемен күрсәтү сорала. Җавапның аерым бер элементын күрсәтү бәяләнми.) Барлыгы 8 балл.

1.	2.

3.

4.

5.

6.

Жавап:_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

12. Советлар Союзы геройларының исемнәрен атагыз һәм алырның кыскача батырлыкларын билгеләгез. Исемнәрен дөрес атау өчен 3 балл. Батырлыкларын тасвирлаган өчен 3 балл. Барлыгы 18 балл.

1. - **2. -** **3. -**

1._____

_____

_____

_____

_____

_____

2._____

_____

_____

_____

_____

_____

3. _____

_____

_____

_____

_____

_____

_____